| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>СТЕПНОШЕНТАЛИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>КЫР ШОНТАЛЫ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

с. Степная
Шентала

РЕШЕНИЕ КАРАР

15.08.2022 № 31

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Кыр Шонталы авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 2004 елның 29 декабрендәге 190 – ФЗ номерлы 31 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131 – ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 20 пунктына таянып,

**Кыр Шонталы авыл җирлеге советы карар итте:**

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Кыр Шонталы авыл җирлеге Советының 10.04.2013 ел, №56 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Кыр Шонталы авыл авыл җирлендә җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләре турында» гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Территориаль зона **Ж1 – шәхси торак төзелеше зонасы,** җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның **түбәндәге төп төрләре** белән тулыландырырга: авыл хуҗалыгы кулланышы; шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен; торак төзелеше; шәхси торак төзелеше өчен; блокланган торак төзелеше; күчмә торак; урта катлы торак төзелеше; автотранспортны саклау; үз ихтыяҗлары өчен гаражлар урнаштыру; элемтә хезмәте күрсәтү; көнкүреш хезмәте күрсәтү; сәламәтлек саклау; эшмәкәрлек; спорт; яшелчәчелек алып бару; бакчачылык алып бару.

1.2. Территориаль зона **<u>ОД1 - күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле зона,</u>** җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның **түбәндәге төп төрләре** белән тулыландырырга: авыл хуҗалыгы кулланышы; питомниклар; автотранспортны саклау; капиталь төзелеш объектларыннан җәмәгатьчелек тарафыннан файдалану; коммуналь хезмәт күрсәтү; коммуналь

хезмәтләр күрсәтү; коммуналь хезмәтләр күрсәтүне тәэмин итүче

оешмаларның административ биналары; социаль хезмәт күрсәтү; социаль хезмәт күрсәтү йортлары;халыкка социаль ярдәм күрсәтү; элемтә хезмәте күрсәтү; тулай торак; көнкүреш хезмәте күрсәтү; сәламәтлек саклау; мәгариф һәм белем бирү; мәдәни үсеш; фәнни эшчәнлекне тәэмин итү; эшмәкәрлек; эшлекле идарә; сәүдә объектлары (сәүдә үзәкләре, сәүдә-күңел ачу үзәкләре (комплекслар); базарлар; кибетләр; банк һәм иминият эшчәнлеге; җәмәгать туклануы; кунакханә хезмәте күрсәтү; күңел ачу;күңел ачу чаралары; күңел ачу чаралары; хезмәт урыны гаражлары; автомобиль юу урыннары; автомобильләрне ремонтлау; спорт; элемтә; фәнни-житештерү эшчәнлеге.

1.3. Территориаль зона **СХ1 – авыл хуҗалыгы җирләре зонасы** жир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның **түбәндәге төп төрләре** белән тулыландырырга: авыл хуҗалыгы кулланышы; үсемлекчелек; бөртекле һәм башка авыл хуҗалыгы культураларын үстерү; яшелчәчелек; тонизацияли торган, дару, чәчәк культуралары үстерү; бакчачылык; йөзем үстерү; җитен һәм киндер үстерү; терлекчелек; эре терлекчелек; җәнлекчелек; кошчылык; дуңгызчылык; умартачылык; балык үрчетү; авыл хуҗалыгын фәнни яктан тәэмин итү; авыл хуҗалыгы продукциясен саклау һәм эшкәртү; кыр шартларында шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару; питомниклар; авыл хуҗалыгы җитештерүен тәэмин итү; печән чабу; авыл хуҗалыгы хайваннарын көтү; эчке хокук тәртибен тәэмин итү; яшелчәчелек алып бару; бакчачылык алып бару.

1.4. Территориаль зона **СХ2 – авыл хуҗалыгы предприятиеләрен һәм корылмаларын урнаштыру зонасы** җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның **түбәндәге төп төрләре** белән тулыландырырга: авыл хуҗалыгы кулланышы; үсемлекчелек; бөртекле һәм башка авыл хуҗалыгы культураларын үстерү; яшелчәчелек; тонизацияли торган, дару, чәчәк культуралары үстерү; бакчачылык; йөзем үстерү; җитен һәм киндер үстерү; терлекчелек; эре терлекчелек; җәнлекчелек; кошчылык; дуңгызчылык; умартачылык; балык үрчетү; авыл хуҗалыгын фәнни тәэмин итү; авыл хуҗалыгын фәнни яктан тәэмин итү; авыл хуҗалыгы продукциясен саклау һәм эшкәртү;кыр шартларында шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару; питомниклар; авыл хуҗалыгы җитештерүен тәэмин итү; печән чабу; авыл хуҗалыгы хайваннарын көтү; эчке хокуый тәртипне тәэмин итү; яшелчәчелек алып бару; бакчачылык алып бару.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга https://alekseevskiy.tatarstan.ru.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

4. Карар халыкка рәсми рәвештә җиткерелгәннән соң үз көченә керә.

**Алексеевск муниципаль районы Кыр Шонталы авыл җирлеге Башлыгы, Совет Рәисе** **Ф.Я.Хәммәдиев**

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ "СТЕПНОШЕНТАЛИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ" АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН СОВЕТ СТЕПНОШЕНТАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ